**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 07.04.2022** **№ 399**

# 2020-2024 елларга Биектау муниципаль районы халкы арасында җәмәгатьчелек сәламәтлеген ныгыту өлкәсендә муниципаль программаны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 01 июлендәге 461 номерлы карарын үтәү йөзеннән КАРАР БИРӘ:

1. «2020-2024 елларга Биектау муниципаль районы халкы арасында җәмәгатьчелек сәламәтлеген ныгыту» максатчан программасын кушымта нигезендә расларга.

2. «Биектау үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә әлеге программаны тормышка ашыруны координацияләүне гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә.

3. «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ ел саен Биектау муниципаль районы бюджетын чираттагы финанс елына формалаштырганда, программа чараларын гамәлгә ашыру өчен, Биектау муниципаль районы бюджетыннан һәм муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан шушы максатларга җибәрелә торган акчаларны күздә тотарга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча игълан итәргә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Д.Ф.Шәйдуллин

Кушымта

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 07.04.2022 № 399нче номерлы карары белән

# 2020-2024 елларга Биектау муниципаль районы халкы арасында җәмәгатьчелек сәламәтлеген ныгыту өлкәсендә муниципаль программа

**2020-2024 елларга Биектау муниципаль районы халкы арасында җәмәгатьчелек сәламәтлеген ныгыту өлкәсендә муниципаль программа**

ПАСПОРТ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2020-2024 елларга Биектау муниципаль районы халкы арасында җәмәгатьчелек сәламәтлеген ныгыту өлкәсендә<br>муниципаль программа |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон (2013 ел, 27.09 редакциясендә), «Әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тарту нәтиҗәләреннән гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы (2013 ел, 23.07 редакиясендә) Федераль закон (01.09.2013 белән үз көченә керүче үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), “Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында” 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон (2013 ел, 02.07 редакциясендә) |
| Программаны эшләүче | «Биектау район үзәк хастаханәсе» ДАССУ |
| Программаның максаты | Биектау районы халкының социаль-нәтиҗәле сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;<br>Алкоголь продукциясен һәм тәмәке тартуны чамадан тыш куллануны киметү, алкоголизмны һәм тәмәке тартуны профилактикалау |
| Программаның бурычлары | 1. Сәламәт яшәү рәвеше формалаштыруның бердәм системасын булдыру, сәламәтлекне актив саклап калу һәм ныгыту, район халкының уртача гомер озынлыгын һәм тормыш сыйфатын арттыру.<br>2. Социаль әһәмиятле авырулардан үлүчеләр санын киметү.<br>3. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү.<br>4. Халыкка авыруларны профилактикалау турында мәгълүмат бирү һәм аның буенча күнекмәләргә өйрәтү, үз сәламәтлегеңне саклап калуның, үз-үзеңне тотуның индивидуаль моделен төзү. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2020-2024 еллар |
| Ярдәмче | 1. Каты алкогольле эчемлекләрне сату вакытын |

| | |
|---|---|
| программалар һәм төп чаралар исемлеге | чикләү.<br>2. Медицина профилактикасы хезмәтен үстерү. |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме 305мең сум тәшкил итә.<br>Биектау муниципаль районы бюджеты - 183 мең сум, шул исәптән өстәмә рәвештә алынган керемнәр булганда - 156 мең сум.<br>Бюджеттан тыш чаралар - 122 мең сум. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | Халык үлемен киметү (барыннан да элек, кан әйләнеше системасы авырулары, имгәнүләр һәм агуланулар, яман шешләр баарлыкка килү белән бәйле рәвештә), гомер озынлыгын, туучылар санын һәм халыкның табигый үсешен арттыру.<br>Гражданнарның үз сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен индивидуаль җаваплылыгын арттыру. |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты. |

**2020-2024 елларга Биектау муниципаль районы халкы арасында җәмәгатьчелек сәламәтлеген ныгыту өлкәсендә муниципаль программаны төп программа чаралары**

| № тб | Чараларның исеме | Үтәү срогы (еллар) | Финанслау чыганаклары (мең сум) | | | | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ТР бюджеты | Муниципаль бюджет | Бюджеттан тыш чыганаклар | Барлыгы | |
| 1 | 2 | 3 | | 4 | 5 | 6 | 7 |
| **1. Сәламәт яшәү рәвешен булдыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү буенча оештыру чаралары** | | | | | | | |
| 1.1. | Җәмәгать оешмаларын җәлеп итеп, ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең (оешмаларның) хезмәт коллективларында сәламәт яшәү рәвеше өчен хәрәкәт формалаштыру | 2020-2024ел. | - | - | 5.0<br>5.0 | 5.0<br>5.0 | Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары;<br>«ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ |
| 1.2. | Барлык милек формасындагы учреждениеләрнең (оешмаларның) коллектив шартнамәләренә, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләренә тәмәке тартмаучы, тәмәке тартудан баш тарткан һәм сәламәт яшәү рәвеше алып баручы хезмәткәрләрне матди бүләкләү чаралары кертү. | 2020-2024ел. | - | - | 3.0<br>3.0 | 3.0<br>3.0 | Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары; учреждениеләр, предприятиеләр, оешмалар җитәкчеләре |
| 1.3. | «Әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тарту зыяннарыннан гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль законны бозуларны ачыклау һәм булдырмау | 2020-2024ел. | - | - | - | - | Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары; Биектау муниципаль районы буенча ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы бүлеге |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | өчен милекнең төрле формаларындагы сәүдә һәм җәмәгать туклануы объектларын комплексly тикшерүләр оештыру | | | | | | |
| 1.4. | “Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында” 2010 елның 22 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү | 2020-2024ел. | - | - | - | - | Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары |
| 1.5. | Барлык милек рәвешләрендәге учреждениеләрдә (оешмаларда) тәмәке тартуның зыяны һәм нәтиҗәләре турында күрсәтмә мәгълүмат урнаштыру | 2020-2024ел. | - | - | 3.0<br>3.0 | 3.0<br>3.0 | Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары; учреждениеләр, предприятиеләр, оешмалар җитәкчеләре |
| 1.6. | Яшь кешеләргә тәмәке эшләнмәләрен паспорт күрсәтү буенча сату. 18 яшькә кадәрге затларга тәмәке эшләнмәләрен сатуны тыю. | 2020-2024ел. | - | - | - | - | Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары; Биектау муниципаль районы буенча ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы бүлеге |
| 1.7. | 18 яшькә кадәрге затлар белем алган мәгариф учреждениеләрен (мәктәпләрне һәм башка уку йортларын) төтен детекторлары белән җиһазландыру. | 2020-2024ел. | - | 90,0(өстәмә керемнәр булганда) | - | 90,0 | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ Мәгариф бүлеге» МКУ |
| 1.8. | «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы | 2020-2024ел. | - | - | - | - | Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары; Биектау муниципаль районы буенча ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы бүлеге |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Федераль законны үтәү | | | | | | |
| 1.10. | Медицина хезмәтенең алкогольгә бәйле затларны рухи реабилитацияләүне гамәлгә ашыручы традицион конфессияләр, иҗтимагый берләшмәләр белән хезмәттәшлеге, | 2020-2024ел. | - | - | - | - | Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары; «Биектау РҮХ» ДАССУ |
| 1.11. | Махсуслаштырылган социаль-психологик хезмәтләрне үстерү. | 2020-2024ел. | - | - | - | - | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Биектау муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе; «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ Мәгариф бүлеге» МКУ |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **2. Яшьләр арасында тәмәке, алкоголь продукциясе һәм сыра куллануны профилактикалау** | | | | | | | |
| 2.1. | «Тәмәке төтенсез район» еллык массакүләм профилактика акциясен тематик матбугат конференцияләре, семинарлар, конкурслар, күргәзмәләр үткәрү белән оештыру. | 2020-2024ел. | - | 10,0(өстәмә керемнәр булганда) | - | 10,0 | «ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ, «Биектау РҮХ» ДАССУ, «Татмедиа» ААҖ «Биектау хәбәрләре» газетасы редакциясе филиалы |
| 2.2. | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, зарарлы гадәтләрне, шул исәптән тәмәке тарту, алкоголь продукциясен һәм сыраны куллануны җиңеп чыгу мәсьәләләрен массакүләм мәгълүмат чараларында системалы рәвештә яктырту | | - | - | - | - | «Татмедиа» ААҖ «Биектау хәбәрләре» газетасы редакциясе филиалы, «Биектау РҮХ» ДАССУ |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.3. | Яшьләрне һәм эшләүче халыкны анкеталаштыру ысулы белән никотин һәм алкогольгә бәйлелек дәрәҗәсен һәм алкоголизация һәм тәмәке тарту проблемаларына мөнәсәбәтен өйрәнү. | 2020-2024ел. | - | 4.0<br>4.0 | - | 4.0<br>4.0 | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ Мәгариф бүлеге» МКУ; «ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ, «Биектау РҮХ» ДАССУ |
| 2.4. | Социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләр каршында сәламәтлек «мәктәпләре» эшен оештыру. | 2020-2024ел. | - | - | - | - | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Биектау муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе |
| 2.5. | Педагогик хезмәткәрләр өчен заманча превентив технологияләр буенча өйрәтү семинар-тренинглары үткәрү. | 2020-2024ел. | - | - | - | - | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ Мәгариф бүлеге» МКУ; «Биектау РҮХ» ДАССУ |
| 2.6. | Мәктәп яшендәге балаларга һәм районның башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларга ел саен профилактик медицина тикшерүе үткәрү, шул исәптән наркотик матдәләрне һәм психотроп матдәләрне медицина булмаган куллануга юл куючы затларны ачыклау өчен. | 2020-2024ел. | - | - | 100,0 | 100,0 | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ Мәгариф бүлеге» МКУ; «Биектау РҮХ» ДАССУ |
| 2.7. | Биектау РҮХ ДАССУнең наркология кабинетында тәмәке тартудан баш тарту мәсьәләләре буенча консультацияләр оештыру | 2020-2024ел. | - | - | - | - | «Биектау РҮХ» ДАССУ |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.8. | Балалар, яшьләр һәм аларның ата-аналары арасында педиатрлар, психиатрлар, нарколог табибларны, полиция хезмәткәрләрен җәлеп итеп, балаларда һәм яшүсмерләрдә зарарлы гадәтләрне профилактикалау буенча лекцияләр, әңгәмәләр үткәрү | 2020-2024ел. | - | - | - | - | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ Мәгариф бүлеге» МКУ; «ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ, «Биектау РҮХ» ДАССУ |
| 2.9. | Мәдәният учреждениеләрендә тәмәке тартуның, алкоголь продукциясен һәм сыра куллануның зыяны турында ел саен уздырыла торган китап-иллюстратив күргәзмәләр, мәгълүмат көннәре, видеолекторийлар һәм башка чаралар оештыру. | 2020-2024ел. | - | 10,0 | - | 10,0 | Үзәк китапханә, |
| 2.10. | Һәркем файдалана ала торган китапханәләрне яшьләр арасында тәмәке тартуны чикләү проблемасы буенча мәгълүмати һәм методик әсбаплар белән тәэмин итү. | 2020-2024ел. | - | 5,0 | - | 5,0 | Үзәк китапханә, «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ Мәдәният бүлеге» МКУ |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **3. Спорт һәм массакүләм физик культураны үстерү чаралары** | | | | | | | |
| 3.1. | Яңа спорт корылмаларын төзү һәм файдалануга кертү, йорт яны территорияләрен һәм торак массивларын спорт һәм уен мәйданчыклары белән тәэмин итү. | 2020<br>2024 | - | - | - | - | Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары |
| 3.2. | Яшәү урыннары буенча төрле яшьтәге халыкның киң катнашында физкультура-савыктыру һәм массакүләм спорт чаралары үткәрү | 2020<br>2024 | | 25,0<br>(өстәмә керемнәр | | 25,0 | «ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | булганда) | | | |
| 3.3. | Яшәү урыны буенча физкультура-спорт юнәлешле клуб берләшмәләрен ачу | 2020 2024 | - | - | - | - | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ Мәгариф бүлеге» МКУ; «ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ; Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары |
| 3.4. | Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында спорт эшен оештыру, адаптив физик культура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру. | 2020 2024 | - | 30,0 () | - | 30,0 | «ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ |
| 3.5. | Мәгариф учреждениеләре арасында физкультура-савыктыру һәм спорт-массакүләм эшне иң яхшы оештыруга смотр-конкурслар үткәрү. | 2020-2024г. | - | 5.0 (өстәмә керемнәр булганда) | - | 5.0 | «ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ |